ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

# КАРАР

№259 26.03.2015ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Совет каршында яшьләр парламентын булдыру турында.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән җайга салу, яшьләр проблемаларын чишү буенча тәкъдимнәр әзерләү, хокукый эшчәнлек күнекмәләрен үзләштерүдә яшьләр өчен шартлар тудыру өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү максатыннан Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршында яшьләр парламентын булдырырырга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы муниципаль Яшьләр парламенты турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты Рәисе

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы яшьләр иҗтимагый палатасы әгъзасы, Аксубай муниципаль районыннан аның составына сайланган Борисова Анна Николаевнаны расларга.

- 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламентын формалаштыру максатыннан эшче төркем оештырырга.

4. Эшче төркемгә 2015 елның 30 мартына кадәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты составын формалаштырырга һәм расларга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы турында рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubsyevo.tatarstan.ru

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов

Аксубай муниципаль районы
Советы 26.03.2015 ел № 259 карарына
1 нче кушымта.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районыСовет каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба-яшьләр парламенты) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы эшчәнлегенә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән җайга салу, яшьләр проблемаларын чишү буенча тәкъдимнәр әзерләү, закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүдә яшьләр өчен шартлар булдыру өлкәсендә ярдәм итү максатында төзелә.
2. 2. Яшьләр парламенты Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм яшьләр парламенты регламенты нигезендә иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр парламенты 5 елга формалаша.

## **II**Яшьләр парламентының төп бурычлары

Аксубай муниципаль районы Советы комиссияләренең яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актларны карап тикшерүгә әзерләү эшчәнлегендә катнашу.

1. Яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актлар проектларын эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүдә ярдәм итү. Яшьләр хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә муниципаль хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.
2. 2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә Яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруга иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру.

Яшьләрнең хокукый культурасын күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлтелгән агарту һәм аңлату эшләре алып бару.

## **III.** Яшьләр парламентын формалаштыру составы һәм тәртибе

1. 1. Яшьләр парламенты әгъзалары булып Аксубай муниципаль районы территориясендә 30 яшькә кадәрге гражданнар тора ала.
2. 2. Яшьләр парламенты Татарстан Республикасының республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең район вәкиллекләреннән, Татарстан Республикасында Гомумроссия яшьләр иҗтимагый оешмалары бүлекләреннән, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләрдән, шулай ук «ПолитЗавод» проектының муниципаль этабында катнашучылардан (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы

составына кермәгән) тора.

3. . 2 пунктта күрсәтелгән оешмалар үз утырышларында Яшьләр парламентына бер вәкил сайлыйлар һәм тиешле карарны парламент Советына җибәрәләр.

4. Яшьләр парламенты Советы Сан составын билгели һәм әлеге парламент әгъзаларының вәкаләтләрен раслый.

5. Яшьләр парламенты рәисе итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы яшьләр иҗтимагый палатасы әгъзасы билгеләнә, ул районнан аның составына сайлана.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

1. 1. Яшьләр парламентының беренче утырышы элеккеге чакырылыш Яшьләр парламенты советы, шулай ук беренче утырыш көнен билгели, аңа яшьләр парламенты әгъзаларын чакыра, чакырылганнар исемлеген һәм алып бару тәртибен билгели торган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тәкъдиме буенча чакырыла.
2. Яшьләр парламентының беренче утырышын әлеге парламент рәисе ача.
3. . Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү һәм гади күпчелек белән рәиснең ике урынбасарын, җаваплы секретарьне сайлыйлар, Яшьләр парламентының санлы составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, комиссияләр төзиләр.
4. . Әгәр анда яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, Яшьләр парламенты утырышы хокуклы.
5. 5 Яшьләр парламенты эшчәнлек юнәлешләре буенча тәкъдимнәр әзерли, кабул итә һәм аларны җирле үзидарә органнарына җибәрә.
6. 6 Яшьләр парламентының карарлары һәм тәкъдимнәре, әгәр алар өчен Яшьләр парламенты әгъзаларының күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.
7. 7 Яшьләр парламенты советын вәкаләтләре яшьләр парламенты Регламенты тарафыннан билгеләнә торган рәис җитәкли.

8. Яшьләр парламенты Советы:

Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;
Яшьләр парламентының эш регламентын эшли; Яшьләр парламентының чираттагы елга эш планнарын әзерли һәм аларны Яшьләр парламентын раслауга тапшыра;
Яшьләр парламенты регламенты нигезендә бүтән вәкаләтләр башкара

9. Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча яшьләр парламенты әгъзалары муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларына иҗтимагый башлангычларда ярдәмчеләр буларак тәкъдим ителергә мөмкин.
10. 10. Яшьләр парламенты комиссияләре үз функцияләре нигезендә эш оештыралар һәм яшьләр парламенты утырышларында карау өчен тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерлиләр
11. 11. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук, чакыру буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары вәкилләре, сәяси партияләр һәм сәяси партияләр җитәкчеләре катнаша ала

12. Яшьләр парламенты утырышларын оештыру-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла

Аксубай муниципаль районы
Советы 26.03.2015 ел № 259
карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Совет каршындагы Яшьләр парламентының эшче төркеме

| | |
|---|---|
| Борисова Анна Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы әгъзасы (килештерү буенча), эшче төркем җитәкчесе |
| Зайдуллина Ләйсән Самигулла кызы | район Советының Җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек һәм методик-мәгълүматлаштыру эше бүлеге башлыгы, төркем әгъзасы |
| Зайцев Станислав Юрьевич | район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы (килешү буенча), төркем әгъзасы |
| Васильева Лариса Валентиновна | район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белгече (килештерү буенча) төркем әгъзасы |
| Габдрахманов Марат Арслангали улы | юридик бүлек начальнигы-район Башкарма комитетының юристы, төркем әгъзасы. |